| | |
|---|---|
| ГЛАВА ЛЕШЕВ- ТАМАКСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САРМАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЛӘШӘҮ ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

07 ноябрь 2021 ел Ләшәү Тамак авылы № 3

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Ләшәү Тамак авылы өлешендә 2022 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Ләшәү Тамак авылы, Яшьләр урамы,1а нче йорт адресы буенча урнашкан Ләшәү Тамак авылы мәдәният йорты бинасында 2021 нче елның 17 ноябренә 9.00 сәгатьтә Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Ләшәү Тамак авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләп кую.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: I нче группа инвалидлар, караучысыз ялгыз өлкәннәр, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан кала, Ләшәү Тамак авыл җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2022 елда үзара салымны 300 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

1) Ләшәү Тамак авылы урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампочкалар һәм яктырткычлар сатып алу);
2) Ләшәү Тамак авылында "МТЗ-82" тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, һәм машина йөртүче хезмәте өчен түләү);
3) Ләшәү Тамак авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, юбилейлар, Җиңү көне, Өлкәннәр көне, Яңа ел) үткәрү өчен бүләкләр алу;
4) "Сарман" район газетасында некролог бастыру;
5) Җәйге чорда авыл территориясен чабу өчен бензокосилкага ГСМ алу;
6) Ләшәү Тамак авылы мәдәният йортына музыкаль аппаратура сатып алу;
7) Ләшәү Тамак авылы эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш җәелгән чокырлар ремонтлау, вак таш ташу);

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Ләшәү Тамак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында, http://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга .

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы

Ләшәү Тамак авыл җирлеге башлыгы: Хабибуллин И.З.